ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.05.2024**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1418**

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсендәге кайбер оешмалар хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмен арттыру һәм «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсендәге кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәте өчен түләүне җайга салу максатларында, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсендәге кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 ел, 20 август, 1557 нче; 2022 ел, 17 гыйнвар, 42 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 2560 нчы; 2022 ел, 14 октябрь, 2730 нчы; 2022 ел, 12 декабрь, 3624 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) билгеләнгән тәртиптә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең,

белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазифаи окладлары күләмнәрен 2024 елның 1 июленнән арттырырга.

2. 2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазифаи окладлары күләмнәрен исәпләү өчен Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмасындагы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазифаи окладлары күләмен 1,05 тапкырга индексацияләргә һәм аның күләмен 13 323 сум күләмендә билгеләргә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсендәге кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 976 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 ел, 20 август, 1557 нче; 2022 ел, 17 гыйнвар, 42 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 2560 нчы; 2022 ел, 14 октябрь, 2730 нчы; 2022 ел, 12 декабрь, 3624 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 3 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның 4 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга;

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин